Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы
Каргалы авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2023 елның 10 феврале № 32/2

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Каргалы авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Каргалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында» 2019 елның 5 июнендәге 74/3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Чистай шәһәр прокурорының 2023 елның 25 гыйнварындагы 02-08-02-2023 номерлы «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2022 елның 28 декабрендәге 569-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 5 декабрендәге 498-ФЗ номерлы протестын карап, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 42 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2021 елның 27 декабрендәге 97-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, Чистай муниципаль районы Каргалы авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Каргалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында» 2019 елның 05 июнендәге 74/3 номерлы Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Каргалы авыл җирлеге советы карары белән расланган Чистай муниципаль районының «Каргалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. 4 статьяның 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«7. «Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары турында» 2015 елның 25 апрелендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының өлкән һәм кече төркемнәре вазыйфаларын биләү өчен һөнәри белем дәрәҗәсенә карата квалификация таләпләре (урта гомуми белем булган очракта) муниципаль хезмәтнең тиешле вазыйфаи бурычларына җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә катнашу кергән очракта, күрсәтелми.»;
1.2. 11 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 12 пунктча өстәргә:«12) аларга чит ил агенты статусы алу.».

1.3. 20 статьяның 2 пунктының 4 бүлегендә «Россия Федерациясе Пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминият фонды» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә яисә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru)

бастырып чыгарырга, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Каргалы авыл җирлеге
башлыгы М.А. Заһидуллин